РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь 2025г. г. Альметьевск №372

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы 77 номерлы «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе турында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль дәрәҗәләрдә социаль-икътисади үсешне стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 18 декабрендәге 534 номерлы боерыгы нигезендә, «Поташ таулары туристлык кластерын» үзләштерү проектын Әлмәт муниципаль районының комплекслы социаль-икътисади үсеш стратегиясенә кертү турында «Татнефть» ГАҖнең 2025 елның 24 апрелендәге 8246 номерлы мөрәҗәгате белән, 2025 елның 23 маендагы җәмәгать тыңлаулары протоколын карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы 77 номерлы «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 337 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга кушымтада:

1.1.1. 4 бүлек 4.3 бүлекчәсе 4.3.4 пункты алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Куелган стратегик максатларны хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашырырга кирәк:

1. Яңа Никольский авыл җирлегендә урнашкан «Поташ таулары туристлык кластерын» комплексын түбәндәге юнәлешләр буенча үстерү:

- Гольф;

-Тау чаңгысы курорты;

- Туристлык хезмәте күрсәтү;
- Ат спорты;
- Ябык аквапарклы күңел ачу үзәге;
- Заманча сыйфат стандартларына җавап бирә торган шифаханә;
- Инфраструктура элементлары;
- Балалар күңел ачу кластеры;
- Автодром.

2. Медицина туризмын үстерү («Әлмәт районара күп профильле хастаханәсе» ДАССУ төп үсеш объекты булып тора).

3. Әлмәт муниципаль районының эчке туризмны үстерү буенча федераль һәм төбәк максатчан программаларында катнашуы.

4. Әлмәт муниципаль районын Татарстан Республикасы территориясе буенча уза торган гамәлдәге туристик маршрутларга кертү.

5. Әлмәт муниципаль районы территориясендә туризм һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә инвестиция проектларын эзләү һәм гамәлгә ашыру.

6. Велосипед спортын үстерүне стимуллаштыру һәм һәвәскәрләр арасында велосипедларны популярлаштыру өчен даими массакүләм чаралар оештыру.

7. Әлмәт муниципаль районы вәкилләренең туризм өлкәсендәге тематик күргәзмәләрдә катнашуы.

8. Бер елга республика һәм федераль масштабтагы массакүләм спорт-күңел ачу чаралары графигын әзерләү һәм аны мәгълүмати яктырту.

9. Татарстан Республикасы территориясе һәм күрше регионнар буенча турларны гамәлгә ашыручы туроператорлар вәкилләре өчен Әлмәт муниципаль районының туристик мөмкинлекләрен тәкъдир итү.

10. «Акташ провалы» табигый объектын төзекләндерү һәм популярлаштыру.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Миллер В.А.).

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы — Р.Е. Әфләтунова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
•СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА•